КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 28 июль г.Казань № 906

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы яисә җирле үзидарә органы буйсынуындагы медицина оешмасын бетерү турында, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату турында карар кабул итүдән килгән зыянны бәяләүне, әлеге әлеге бәяләү критерийларын да кертеп, уздыру тәртибен һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы яисә җирле үзидарә органы буйсынуындагы медицина оешмасын бетерү турында, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату турында карар кабул итүдән килгән зыянны бәяләү бәяләү комиссиясен төзү, аның эшен оештыру һәм бәяләмәләр әзерләү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 2 октябрь, 896 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы яисә җирле үзидарә органы буйсынуындагы медицина оешмасын бетерү турында, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату турында карар кабул итүдән килгән зыянны бәяләүне, әлеге әлеге бәяләү критерийларын да кертеп, уздыру тәртибен һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы яисә җирле үзидарә органы буйсынуындагы медицина оешмасын бетерү турында, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату

турында карар кабул итүдән килгән зыянны бәяләү бәяләү комиссиясен төзү, аның эшен оештыру һәм бәяләмәләр әзерләү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 2 октябрь, 896 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы яисә җирле үзидарә органы буйсынуындагы медицина оешмасын бетерү турында, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату турында карар кабул итүдән килгән зыянны бәяләүне, әлеге әлеге бәяләү критерийларын да кертеп, уздыру тәртибен һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы яисә җирле үзидарә органы буйсынуындагы медицина оешмасын бетерү турында, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату турында карар кабул итүдән килгән зыянны бәяләү бәяләү комиссиясен төзү, аның эшен оештыру һәм бәяләмәләр әзерләү тәртибен раслау турында»

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына яисә җирле үзидарә органына буйсынган медицина оешмасын бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне уздыру, бу бәяләүнең критерийларын да кертеп, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату тәртибенең 5 пунктындагы икенче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына яисә җирле үзидарә органына буйсынган медицина оешмасын бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне уздыру, аның эшен оештыру һәм бәяләмәләр әзерләү, аның аерымланган бүлекчәсе эшчәнлеген туктату тәртибенең 2 пунктында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы<br>
Премьер-министры А.В.Песошин